ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 1 (1); 2001, № 3; 2004, № 3 (IV өлеш); 2005, № 4 (I өлеш), № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3, № 6 (I өлеш); 2013, № 6 (II өлеш), № 11 (II өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 54 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 37 (I өлеш); 2021, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяда:
а) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: «Аларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең класслы чиннары бирелә. Җәмәгать судьясы аппараты хезмәткәрләре шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны да били ала.»;
б) 3 пунктта «штат расписаниесе» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы Судьялар советы фикерен исәпкә алып,» сүзләрен өстәргә;

2) 10 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6. Җәмәгать судьяларының мәгълүмат ресурсларын берләштерелгән белешмәләр базаларына һәм белешмәләр банкларына кертү чаралары, аларны алып баруның һәм алардан файдалануның бердәй технологияләрен эшләү, суд эшләрен һәм эш башкаруны алып бару өчен кирәкле мәгълүмат системаларын булдыру һәм билгеләү, бердәй принциплар һәм гомуми кагыйдәләр нигезендә эшләүче мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдалануга карата бердәй техник

таләпләр билгеләү Россия Федерациясе Югары Суды каршындагы Суд департаменты һәм Татарстан Республикасында Суд департаменты идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ
БҮЛЕК
ОБЩИЙ
ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 10 октябрь
№ 71-ТРЗ